**Татарстан Республикасы һәм**
**Ленинград өлкәсе Хөкүмәте арасында**
**сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль һәм**
**мәдәни хезмәттәшлек турында**

# КИЛЕШҮ

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов йөзендә Татарстан Республикасы бер яктан, Ленинград өлкәсе Уставы нигезендә эш итүче Ленинград өлкәсе Губернаторы Дрозденко Александр Юрьевич йөзендә Ленинград өлкәсе Хөкүмәте икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталып,

Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясенең һәм Якларның башка норматив хокукый актларына нигезләнеп,

үз хокукларын һәм вәкаләтләрен Россия Федерациясенең тигез хокуклы субъектлары буларак гамәлгә ашырып,

тотрыклы һәм озак вакытка исәпләнгән ике яклы элемтәләрне киләчәктә дә үстерүдә һәм ныгытуда үзара кызыксыну күрсәтеп, Якларның социаль-икътисадый үсешендә үзара кызыксынганлыгы принципларына, Татарстан Республикасы һәм Ленинград өлкәсе территорияләрендә эшчәнлек алып баручы хуҗалык субъектлары арасында базар мөнәсәбәтләрен үстерү өчен уңай шартлар булдыруга нигезләнеп,

түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

1 статья

Яклар инде булдырылган сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм мәдәни элемтәләрне дуслык, ышаныч һәм үзара хөрмәт рухында үстерә, тигезлек, партнерлык һәм үзара файда нигезендә, аның өчен тиешле оештыру, икътисадый, хокукый һәм башка кирәкле шартлар тудырып, хезмәттәшлек итә.

2 статья

Яклар уртак проектларны эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтә, Татарстан Республикасы һәм Ленинград өлкәсе территорияләрендә эшчәнлек алып баручы хуҗалык субъектларының федераль һәм төбәк программаларын гамәлгә ашыруда катнашуына ярдәм итә.

3 статья

Яклар фәнни-техник, икътисадый һәм хокукый мәгълүмат алмаша, Яклар территорияләрендә эшчәнлек алып баручы хуҗалык субъектларының үзара

хезмәттәшлегенә һәм уртак күргәзмәләр, ярминкәләр уздыруга булышлык күрсәтә.

Яклар бизнес-миссияләр оештыруга, эшкуарлар җәмгыятьләре арасында эшлекле элемтәләр урнаштыру һәм аларны ныгытуга, эшкуарлар арасында эшлекле очрашулар уздыруга ярдәм итә.

4 статья

Яклар сәламәтлек саклау, фән, мәдәният, мәгариф, халыкны социаль яклау, гаилә һәм гендерлык сәясәте, демографик үсеш, физик культура һәм спорт, дәүләт яшьләр сәясәте, хезмәт мөнәсәбәтләре, халыкны эш белән тәэмин итү, миграция, эшкуарлык эшчәнлеге, урман хуҗалыгы, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә хезмәттәшлек итә.

5 статья

Яклар инвестицияләр җәлеп итү, инвестиция климатын яхшырту, инвестиция мәйданчыкларын тәкъдим итүне оештыру тәҗрибәсе алмашуга ярдәм итә, шулай ук Татарстан Республикасы һәм Ленинград өлкәсе территорияләрендә инвестиция форумнары, конференцияләре һәм инвестицияләргә багышланган башка чаралар уздыру турында мәгълүмат бирә.

6 статья

Яклар Татарстан Республикасы һәм Ленинград өлкәсе туристлык тармагында мөмкинлекләре турында реклама-мәгълүмати материаллар алмашу юлы белән ике яклы чаралар уздырганда туристлык өлкәсендә хезмәттәшлек урнаштыруга ярдәм итә.

7 статья

Дәүләт-хосусый партнерлык нигезендә гамәлгә ашырыла торган транспорт һәм юл хуҗалыгын үстерү проектлары гамәлгә ашыру, шәһәр яны һәм муниципальара юлларда халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру, автомобиль транспортын газ-мотор ягулыгын файдалануга күчерү тәҗрибәсен алмашу юлы белән Яклар транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә хезмәттәшлек итә.

8 статья

Яклар бер-берсенә хокукый ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыра, Яклар башкарма хакимият органнары арасында багланышларны киңәйтүгә актив

булышлык итә, закон чыгару һәм хокуктан файдалану эшчәнлегендә, коррупциягә каршы көрәшүдә тәҗрибә уртаклаша.

9 статья

Яклар Россия Федерациясенең дәүләт программаларын, Татарстан Республикасы һәм Ленинград өлкәсе дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында мәгълүмати-коммуникация технологияләрен үстерү мәсьәләләре буенча, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне электрон рәвешкә күчергәндә дә, тәҗрибә уртаклаша.

10 статья

Яклар гражданнарга һәм оешмаларга электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә, ГЛОНАСС системасы сигналларын файдаланып эшләүче спутник навигациясе аппаратурасын, космос өлкәсендәге эшчәнлек, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу очракларын фотога һәм видеога төшерү йомгакларын куллану өлкәсендә хезмәттәшлекне арттыра һәм тәҗрибә алмаша.

11 статья

Яклар электр белән тәэмин итү, кече энергетиканы үстерү, яңартыла торган энергия чыганакларыннан файдалану, инженерлык инфраструктурасы, торак-коммуналь хуҗалык, торак төзелеше һәм электр энергетикасын үстерү программаларын эшләү өлкәсендә мәгълүмат һәм тәҗрибә алмаша.

12 статья

Яклар мәдәният, сәнгать, кинематография, Татарстан Республикасы һәм Ленинград өлкәсе территорияләрендә театр-концерт һәм иҗат коллективлары, музыкаль төркемнәр гастрольләрен, рәсем сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать һәм фотография күргәзмәләрен, фестивальләр, очрашулар, конкурслар, дискуссияләр һәм башка чараларны оештыру өлкәсендә булдырылган багланышларны һәм элемтәләрне ныгытуга һәм үстерүгә ярдәм итә.

Яклар Татарстан Республикасы һәм Ленинград өлкәсе китапханәләр системасы арасында үзара файдалы хезмәттәшлеккә, шулай ук китапханә эше өлкәсендә тәҗрибә уртаклашуга ярдәм итә.

Яклар мәдәният, сәнгать, кинематография өлкәсендә мәдәни мирас объектларын саклап калу, файдалану һәм популярлаштыру өлкәсендә, шул исәптән әлеге өлкәгә идарә итү системасын камилләштерү эшендә заманча инновацияле технологияләр файдалану буенча да, мөнәсәбәтләрне җайга

салучы дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру эшенә кагылышлы мәгълүмат һәм тәҗрибә алмаша.

13 статья

Әлеге Килешү Яклар тарафыннан хезмәттәшлекнең тәгаен өлкәләрендә төбәкара программалар, проектлар һәм чаралар планнары эшләү өчен нигез булып тора.

14 статья

Әлеге Килешүнең нигезләмәләрен гамәлгә ашыруга ярдәм итү һәм Яклар тарафыннан әлеге Килешүгә нигезләнеп кул куелган карарлар, шартнамәләр, чаралар планнары үтәлүе барышын тикшереп тору максатларында Яклар ике яклы сөйләшүләр уздыра һәм уртак эш төркемнәре төзи ала.

15 статья

Әлеге Килешү Якларның һәр икесенең өченче як белән төзелгән килешүләрендә (шартнамәләрендә) билгеләнгән йөкләмәләренә кагылмый.

Әлеге Килешүне гамәлгә ашырганда аның нигезләмәләрен төрлечә шәрехләү һәм куллану мөмкин булса, мондый хәлләрдән чыгу Яклар тарафыннан үзара консультацияләр һәм сөйләшүләр уздыру юлы белән хәл ителә.

Әлеге Килешү аңа кул куйган Якларга финанс һәм милек бурычлары йөкләми.

16 статья

Килешү Яклар тарафыннан аларның уртак ризалыгы белән үзгәртелә ала. Барлык үзгәрешләр Якларның вәкаләтле вәкилләре кул куйган аерым өстәмә килешүләр белән рәсмиләштерелә.

17 статья

Килешү 5 елга төзелә һәм аңа кул куелган вакыттан үз көченә керә.

Әгәр дә Якларның берсе дә әлеге Килешүнең гамәле чыгарга кимендә алты ай кала, икенче Якка Килешүнең гамәлен туктатырга нияте барлыгы турында язма рәвештә хәбәр итмәсә, әлеге Килешүнең гамәле киләсе биш елга үзеннән-үзе озайтыла.

Якларның һәрберсе, икенче Якка аны өзү ниятләнгән датага кимендә өч ай кала язмача хәбәр итеп, бер яклы тәртиптә әлеге Килешүне өзәргә хокуклы.

2016 елның «17» июнендә Санкт-Петербург шәһәрендә һәр Як өчен берәр нөсхәдә, һәрберсе рус һәм татар телләрендә ике нөсхәдә башкарылды.

Нинди дә булса төгәлсезлекләр яисә терминнарның мәгънә ягыннан эчтәлеге туры килмәү очраклары килеп чыкса, рус телендәге текст өстенлекле була.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы өчен | Ленинград өлкәсе Хөкүмәте өчен |
| Татарстан Республикасы Президенты | Ленинград өлкәсе Губернаторы |
| **Р.Н. Миннеханов** | **А.Ю. Дрозденко** |

20.06.2016
№ 21